МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** 156-п

Казан шәһәре

**БОЕРЫК** 20.02.2018

**Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы адресы буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналарын оештыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләрнең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә, җир асты байлыкларыннан файдалануга 21.04.2017 ТАТ АРС 01739 ВЭ лицензияне һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсенең Арча, Биектау районнарындагы территориаль бүлегенең дәүләт санитария-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килү турында 01.03.2017 №16.03.02.000.Т.000001.03.17 санитария-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы адресы буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учрежде-ниесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналарын оештыру проекты нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы адресы буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналарын оештыру проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психонев-рология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналары чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психонев-рология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналары чикләрендә территориядән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2018 елның 20 февралендәге
156-п номерлы боерыгына 1
нче кушымта

**Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы адресы буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналары чикләре**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү Татарстан Репубпликасы Арча муниципаль районы авылында учреждение территориясендә бер-берсеннән 24 метр аралыкта урнашкан №1 һәм №2 су алу скважиналары ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№1 скв.: төньяк киңлектәге 56°08'49,47", көнчыгыш озынлыктагы 50°14'40,01";

№2 скв.: төньяк киңлектәге 56°08'51,27", көнчыгыш озынлыктагы 50°14'39,20".

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

<u>Санитар саклык зонасының I поясы.</u>

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең җир астыннан су алу корылмасының санитар саклык зонасындагы беренче пояс чиге фактик койма дәрәҗәсендә билгеләнә

| Скважина номеры | Скважиналар авызыннан коймага кадәрге ераклык, м | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Төньяк-көнбатышка таба | Көньяк-көнбатышка таба | Төньяк-көнчыгышка таба | Көньяк-көнчыгышка таба |
| 1 | 68 | 31 | 19,7 | 27 |
| 2 | 13,7 | 20 | 24,4 | 94,8 |

<u>Санитар саклык зонасының II поясы</u>

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең №1 һәм №2 су алу скважи-наларында санитар саклык зоналарының икенче пояс чикләре һәр скважинадан 31 метрлы радиус белән билгеләнә.

Су алу скважиналарын санитар саклык зоналарының II пояс чикләре кисешкәнлектән, аларны берләштерергә мөмкин.

Санитар саклык зонасының III поясы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең №1 һәм №2 скважиналарының санитар саклык зоналарында өченче пояс һәр скважинадан 208 метр билгеләнә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең №1 һәм №2 скважиналарының санитар саклык зоналарында өченче пояс чикләре кисешкәнгә күрә, аларны гомуми өченче пояс чиге буларак берләштерергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының 2018
елның 20 февралендәге 156-
п номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы адресы буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганагында (№1 һәм №2 скважиналар) санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган

проект җитештерү-чәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры ки-лүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайлан-маларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры

Р. М. Гарипов, 2016 ел.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү өчен каралган җир асты чыганагының (1 нче һәм 2 нче су алу скважиналарын) санитар саклау зоналарын оештыру проекты

Казан шәһәре, 2016 ел.

ПРОЕКТНЫ БАШКАРУЧЫ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Проект «Центр экологического сопровождения» ҖЧҖ эшләнде

Юридик адрес: 420139, ТР, Казан шәһәре, Рихард Зорге урамы, 87 йорт, 108 фатир

Фактик адрес: 420073, ТР, Казан шәһәре, Гвардия урамы, 15 йорт, 710 офис

ИНН: 1601001875

КПП: 156901001

ОГРН: 1121674004869

Директор Корбанова Э.З.

ЭЧТӘЛЕК


Кереш 4

Предприятие турында белешмә 5

1. Су алу җайланмаларына характеристика 6
2. Су алу җайланмалары санитар саклау зоналарының хәзерге санитар халәте 8
3. Эш башкарылган районга кыскача геологик һәм гидрологик характеристика 11
4. Су алу җайланмаларының санитар саклау зоналары расчеты 15
5. Су алу җайланмаларының санитар саклау зоналары территориясендәге санитар чаралар планы 20
6. Җир асты чыганакларының санитар саклау зонасы территориясендәге чаралар 23

6.1. Санитар саклау зонасы поясы буенча чаралар 23

6.2. Санитар саклау зоналарының II һәм III поясы буенча чаралар 23

Кулланылган әдәбият исемлеге 25

Кушымталар исемлеге 26

Кушымта 1. Төзелеш перспективалары турында белешмә

Кушымта 2. №1 һәи №2 скважиналарының паспорты

Кушымта 3. Суны тикшерүнең лаборатория беркетмәләре

Кушымта 4. Гидрологик нәтиҗә

Рәс.1. Районның күзәтү картасы

Рәс.2. Схематик гидрологик карта

Рәс.3. 1-1 линиясе буенча геологик-гидрологик кисем

Рәс.4. Гидрологик карта һәм кисемдәге шартлы билгеләр

Рәс.5. Санитар саклау зонасындагы беренче поясның урнашу чикләре схемасы

Рәс.6. Санитар саклау зонасындагы икенче һәм өченче поясларның урнашу чикләре схемасы

Рәс.7. Санитар саклау зонасындагы беренче поясның фотографиясе

# КЕРЕШ

Җир асты суларын алу җайланмаларын санитар саклау зоналарын булдыру — хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган җир асты суларын пычранудан саклау буенча төп чараларның берсе.

Санитар саклау зоналарында режим булдыру һәм режим белән тәэмин итүнең төп максаты су белән тәэмин итү чыганакларын һәм суүткәргеч корылмаларны, шулай ук алар урнашкан территорияләрне санитар саклаудан гыйбарәт.

Санитар сакалу зоналары составына өч пояс керә: беренче пояс — катгый режимлы пояс, икенче һәм өченче пояс — чикләүләр поясы.

Санитар саклау зонасының беренче поясы су алу җайланмалары, барлык суүткәргеч корылмалары һәм су үткәрү каналы урнашкан территорияне үз эченә ала. Ул су алу һәм су үткәрү корылмалары урнашкан урында су чыганагын очраклы яки аңлы рәвештә пычрату мөмкинлеген бетерү максатларында билгеләнә.

Икенче санитар саклау зонасы поясы сулы горизонтны микроблы пычранулардан саклау өчен билгеләнгән. Санитар саклау зонасының икенче поясы чигеннән су алу җайланмасына кадәр араны билгели торган төп параметр - җир асты суларының агымы белән су алу җайланмасына микроблы пычрану өчен исәпләнгән вакыт. Ул патогенлы организмнарның яшәү кытыннан зуррак булырга тиеш.

Өченче санитар саклау зонасы поясы җир асты суларын химик пычранулардан саклау өчен каралаан. Санитар саклау зонасының өченче поясы чикләре су алу җайланмасын эксплуатацияләү вакыты дәвамында җир асты суларының агымы белән химик пычрануга юл куймау шартлары белән билгеләнә. Җир асты суларын алу җайланмаларын проектлаштырганда, су катламына кергән химик матдәләрнең тотрыклы булуын, җир асты сулары һәм токымнары белән үзара бәйләнешкә кермәвен шартлы рәвештә кабул итәләр.

ПРЕДПРИЯТИЕ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

| | |
|---|---|
| Оешма исеме | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе |
| Юридик формасы | Автономияле учреждение |
| ОГРН | 1021606157913 |
| ИНН | 1609002077 |
| КПП | 160901001 |
| ОКПО коды | ОЗ 159379 |
| ОКТМО | 92612462 |
| ОКВЭД | 85.31 |
| Фактик адресы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 34 йорт |
| Юридик адресы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 34 йорт |
| Почта адресы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 34 йорт |
| Расчет счеты | 40601810700023000003 |
| Шәхси счеты | ЛАГО9716ООЗ-НЧ |
| Клиентның банкы | «Ак Барс» ААҖ Банкы, Казан шәһәре |
| Корреспондент счеты | 810000000000805 |
| Банкның идентификацион коды | 049205805 |
| Директор | Гарипов Рамил Мансурович |
| Телефон | 8 (84366) 52 06 |
| Мобиль телефон | 8 9196 20 17 63 |
| Факс | 8 84366 52 2 42 |
| Электрон почта | Zulfiya.Zakiullina@tatar.ru |

# 1. СУ АЛУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫНА ХАРАКТЕРИСТИКА

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе объекты ТР Арча районының Яңа Чүриле авылында (1 рәс) урнашкан.

Учреждение территориясе периметр буенча койма белән әйләндереп алынган, керү урынында контроль-пропуск пункты һәм сак хезмәте бар. Төзелешнең 3 елга каралган перспектив планы кушымтада күрсәтелгән.

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү чыганагы ике су алу скважинасыннан торган җир асты су алу җайланмасыннан гыйбарәт.

Су алу җайланмасы хәзерге вакытта 2,5 метр биеклектәге металл койма белән әйләндереп алынган, аның чикләрендә санитар саклау зоналарының беренче поясына туры килә торган санитар режим саклана.

Скважинаның тирәнлеге -10,0 м, 2005 елда бораулана. Скважина паспорты кушымтада күрсәтелгән.

№ 92 скважинаның тирәнлеге -110,0 м, 2005 елда бораулана. Скважинаның паспорты кушымтада күрсәтелгән.
Скважиналарның эш режимы - елына 365 көн.

Су җыю скважиналарының координатлары:

№1 $56^0$08'49,47 с.ш., $50^0$ 14'40,1"в. д.
№2. $56^0$08'51,27 с. ш., $50^0$ 14'39,2"в. д.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатларында җир асты сулары чыгару белән шөгыльләнә.

Җир асты суыларына ихтыяҗ елына - 34,68 мең м/ел (95 $м^3$/тәүлек), шул исәптән скважинадан - 47,5 $м^3$/тәүлек, №2 скважинадан - 47,5 м $^3$/тәүлекне тәшкил итә.

Скважиналар югары Казандагы карбонат-терригена комплексының (P2kz2) җир асты сулары файдаланыла. Скважиналарның төп характеристикалары № 41 таблицада күрсәтелгән

Таблица №1

Су алу скважиналарының төп билгеләре

| № скв. | Бораулау елы/ тирәнлеге/ тамагының абс.билгесе, м | Су кабул итү өлеше (фильтр) | | Су сыйдыру токымы | Су күләме, м |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Төре | Диаметры, мм/Урнаштыру аралыгы, м | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | 2005/1 10/170 | челтәрле | 133/100-109 | Ташлы ком/P2 $kz^2$ | 35 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 2005/1 10/170 | челтәрле | 133/100-109 | Ташлы ком /P2 $kz^2$ | 35 |

Югары казанлы карбонат-терригена комплексын (P2kz2) эксплуатацияләүче башка су алу скважиналары 5 км радиуста юк.

Карала торган территория тирәсендә су алу җайланмасын санитар саклау зоналары чикләрендәге экологик хәлгә тискәре йогынты ясаучы предприятиеләр юк.

Учреждение территориясе төзекләндерелгән һәм эчке канализация челтәрләре белән җиһазландырылган. Агып җыела торган сулар скважиналардан 400 м ераклыкта урнашкан үзләренең чистарту корылмаларына бүлеп бирелә. Канализация челтәрләре су алу җайланмасы территориясен кисми. Чистартылган агып җыелган суларны скважиналардан 400 м ераклыкта урнашкан кибеп баручы инешкә агызалар.

## 2. СУ АЛУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ САНИТАР САКЛАУ ЗОНАЛАРЫНЫҢ ХӘЗЕРГЕ САНИТАР ХАЛӘТЕ

Скважиналар ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном учреждениесенең киртәләп алынган һәм саклана торган территориясе чикләрендә бер-берсеннән 24 м ераклыкта урнашкан.

№1 су алу скважинасы кирпеч павильон эчендә, 2,4-2,5 м зурлыкта һәм биеклектә урнашкан. Павильонда идән бетонланган. Павильон тирәли бетон «отмостка» бар. Павильон ишеге йозакка бикләнә. Скважина башы идән өстеннән 0,5 м чыгып тора. Аның башы конструкциясе тулы герметизацияне тәэмин итә, ул торбалар арасында һәм артындагы суның пычрану киңлекләренә үтеп керүенә каршы тора.

Скважинаның тамагы герметик ябылган, су пробаларын алу өчен кран бар. Алына торган суның күләмен контрольдә тоту җайланмалары юк. Скважинада су күләменең торышы буенча күзәтүләр алып барылмый (скважина электрүткәргеч белән җиһазландырылмаган).

Скважина ике колонналы төзелешкә ия. 168мм диаметрлы колонна аралыгы белән, 133м диаметрлы эксплуатация колоннасы l-ЛОМ аралыгы белән урнаштырылган. Фильтрның диаметры ул урнаштырылган торбаның диаметрына туры килә һәм ул 133мм тигез. Фильтлау өлеше 100-109 м тирәнлектәге интервалда урнаштырылган.

№1 скважина 56 м тирәнлегенә урнаштырылган, ЭЦВ6-6,5-85 насосы белән җиһазландырылган.

№2 су алу скважинасы кирпеч павильон эчендә урнашкан, аның размеры 2,5х2, 7 м һәм биеклеге 1,93-2,4 м тигез. Павильонда идән бетонланган. Павильон тирәли бетон «отмостка» бар. Павильон ишеге йозакка бикләнә. Скважинаның башы идән өстеннән 0.5 м чыгып тора. Аның башы конструкциясе тулы герметизацияне тәэмин итә, ул торбалар арасында һәм артындагы суның пычрану киңлекләренә үтеп керүенә каршы тора.

Скважинаның тамагы герметик ябылган, су пробаларын алу өчен кран бар. Алына торган суның күләмен контрольдә тоту җайланмалары юк. Скважинада су күләменең торышы буенча күзәтүләр алып барылмый (скважина электрүткәргеч белән җиһазландырылмаган).

Скважина ике колонналы төзелешкә ия. 168м диаметрлы колонна О - м интервалында урнаштырылган. 133м диаметрлы эксплуатация колоннасы 0-110 м интервалында урнаштырылган. Фильтрның диаметры ул урнаштырылган торбаның диаметрына туры килә һәм ул 133мм тигез. Фильтлау өлеше 100-109 м тирәнлектәге интервалда урнаштырылган.

№1 скважина 56 м тирәнлегенә урнаштырылган, ЭЦВ6-6,5-85 насосы белән җиһазландырылган.

Су алу җайланмасының санитар торышы канәгатьләнерлек. Су алу җайланмасы территориясе планлаштырылган, шуңа күрә өслек агымы аның рельефы белән туры килә. Су алу скважиналарына юл каты өслекле түгел. Чит кешеләр үтеп кермәсен өчен су алу җайланмасы территориясе даими рәвештә сакланмый.

Су алу җайланмасы 2,5 м биеклектә, 13,7-90,4 м аралык белән урнаштырылган металл койма белән әйләндереп алынган (№2 таблицаны карагыз).

Таблица 2

Су алу скважиналарының аларны әйләндереп алган корылмага кадәр аралыгы

| Скв.№№ | Аралык, м | | | |
|---|---|---|---|---|
| | төньяк-көнбатышта | көньяк-көнбатыш | төньяк-көнчыгыш | көньяк-көнчыгыш |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 68 | 31 | 19,7 | 27 |
| 2 | 13,7 | 20 | 24,4 | 94,8 |

Су алу җайланмасы территориясендә күләме 10 $м^3$ һәм 15 $м^3$ булган 2 суэтем башнясы бар. №1 скважина тамагыннан күләме 10 $м^3$ булган суэтем башнясына кадәр булган аралык 18,7 м тигез. № 2 скважина тамагыннан күләме 15 $м^3$ булган суэтем башнясына кадәр булган аралык 16,1 м тигез, күләме 10 $м^3$ булган суэтем башнясына кадәр булган аралык — 16 $м^3$.

Су белән тәэмин итү системасы түбәндәгечә: беренче күтәрелеш насосы булган №1 скважинадан су күләме 10 метр булган суэтем башнясына тапшырыла, беренче күтәрелеш насосы булган №22 скважинадан күләме 15 $м^3$ суэтем башнясына тапшырыла. Суэтем башняларыннан алынган су учреждение ихтыяҗларына тотыла.

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесенең җир асты суларын алу сыйфатын өйрәнү «Татарстан Республикасының (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә үткәрелде. Скважиналардан алынган җир асты суларының сыйфаты СанПиН 2.1.4.1074-01» таләпләренә туры килә (кушымта карагыз).

Су алу җайланмасы учреждение корылмаларына бәйсез урында урнашкан. Су алу территориясендә югары вольтлы агачлар, шулай ук чит корылмалар, «Су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары» юк.

Су алу җайланмасын эксплуатацияләүгә турыдан-туры катнашы булмаган объектлар төзү перспективасы планлаштырылмый.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автономияле социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе территориясе төзекләндерелгән, эчке сууткәргеч һәм канализация челтәрләре белән җиһазландырылган. Агып төшә торган сулар скважиналардан 400 м ераклыкта урнашкан чистарту корылмаларына бүлеп бирелә. Канализация челтәрләре су алу җайланмасы территориясен кисми. Чистартылган агып төшкән суларны скважиналардан 400 м ераклыкта урнашкан кибеп баручы инешкә агызалар.

Учреждение территориясендә түбәндәге биналар һәм корылмалар урнашкан: аерым урнашкан алты торак корпус, ашханә, изолятор, столяр һәм тегү остаханәләре, кабул итү-карантин бүлеге, мунча-кер юу комплексы һәм башка ярдәмче бүлмәләр, 2 спорт мәйданчыгы.

Су алу җайланмасыннан якын бина булып төньяк һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә №1 су алу скважинасыннан 18 м ераклыкта һәм № 2 су алу скважинасыннан 24,4 м ераклыкта урнашкан мунча-кер юу корпусы тора.

## 3. ЭШ БАШКАРЫЛГАН РАЙОНГА КЫСКАЧА ГЕОЛОГИК ҺӘМ ГИДРОГЕОЛОГИК ХАРАКТЕРИСТИКА

Геоморфологик яктан су алу участогы Кисьмес һәм Кече Мишә елгалары арасында урнашкан.

Җир асты байлыкларының чыгарыла торган кишәрлеге Кече Мишә үзәненнән (абсолют) су кисеменең тамгасы – 15 м) 4,6 км төньяк-көнчыгышка таба һәм Кисьмес елгасы үзәненнән төньяк-көнбатышка таба 5 км (абс.к су кисү - 120 м) урнашкан.

Кече Мишә елгасы кушылдыгыннан алып исемсез кушылдыгына кадәр ара — 380м.

Карала торган территория су бүлүләрендә 200 м булган абсолют максималь билгеләр һәм елга үзәннәре чикләрендә 98-100 м минималь билгеләр булган калкулык тигезлегеннән гыйбарәт. Елга үзәннәре катламнары киң һәм сай чокырлар, 1,5-2 км озынлыкта һәм 15-20 м тирәнлектә булган иңкүлекләр, шулай ук озынлыгы 4-5 км, ә тирәнлеге 30-40 м җиткән коры үзәннәр рәвешендәге эрозия кисемнәре белән катлауланган. Елга үзәнлекләре кискен ассимметрик формага ия: уң як яры текә, сул ягы – сөзәк

Тектоник яктан караганда, әлеге территория Төньяк-Татар җыелмасының җыелма өлешендә урнашкан. Төче җир асты сулары белән бәйле геологик кисемнең өске өлеше әлеге территориядә Казан һәм Уржум ярусларының урта Пермь һәм элювиаль-делювиаль урта-югары чирек берәмлекләрнең территориаль-карбонат катламнары урнашкан.

Кисемне стратификацияләү Дәүләт геологик картасы битләренең Урта Идел легендасы сериясе нигезендә бирелә – 200 (Түбән Новгород, 2005 ел).

Казан ярусы утырмаларын югары Казан берәмлекләре тәкъдим иткән.

90-140 м егәрлекле югары Казан утырмалары гипс катламнары, доломитлар, мергельләр, комлы, балчык катламнары булган известняклар белән тәкъдим ителгән. Алар 140-190 м абсолют билгедән түбәнрәк урнашкан. 30-60 м егәрлекле Түбән Уржум катламнарының субүләр сыртларында ятучы түшәмәләре кызыл балчык, ташлы ком, мергельләр белән күрсәтелгән. Аларның түбәләрен +135-+200 абсолют билгеләре билгели. Карала торган кишәрлекән читтә урнашкан субүләрләрдә югары аржум катламнары бар. Алар кызыл балчык һәм известьташ катламнары белән түшәлгән. Аларның егәрлеге 25-30 м тигез.

Чирек катламнар карала торган мәйданда шактый киң таралган. Алар Кисмәс , Кече Мишә елгалары һәм аларның кушылдыклары тугайларын берләштерә. Районда карала торган чирек катламнар генезисы буенча аллювиаль, элювиаль-делювиаль катламнар аерып чыгарыла.

Кисмәс, Кече Мишә елгасы һәм аларның кушылдыклары үзәнендә таралыш алган аллювиаль катламнар тугайлыкларны, беренче һәм икенче су баса торган террасаларны берләштерә. Аллювий сирәк чуерташ һәм чуерташ катнашмасы булган ком-балчык составы белән характерлана. Кече елгалар һәм инешләр үзәне буенча аллювий шулай ук, нигездә, җирле токымнарның аз катланган тышлыкларын кертеп, балчыклы материал белән характерлана. Аллювиаль катламнарның максималь егәрлеге – 10-15м.

Чирек элювиаль-делювиаль катламнар нигездә балчык һәм кызыл-көрән, кызыл-буранлы һәм карбонат токымлы вак ташлар белән характерлана. Аларның егәрлеге карала торган районда аз түгел һәм 0,5 м алып 3 м кадәр җитә.

Региональ гидрогеологик районлаштыру буенча, кишәрлек Кама-Нократ артезиан бассейны чикләрендә урнашкан. Россия Дәүләт гидрогеологик картасының Урта-Идел листлар сериясе Урта Идел битләренең җыелма легендасы нигезендә, Дәүләт Геолкартасы 200 битләренең Урта Идел сериясе легендасы белән бәйле рәвештә, токымнарның үтүчәнлеге һәм характерының төреннән һәм зурлыгыннан чыгып, кисүнең өске өлешендә түбәндәге гидростратиграфия бүлекчәләре бүлеп бирелгән:

- түбән үткәрүчәнлеккә ия югары неоптейстоцен-голоценлы силювиаль горизонт;

-локаль көчсез агымлы поликарбонат-триген комплексы (P 2url):

-югары казан терригиена-карбонат комплексы (P2kz2).

Өслектән беренче булып карала торган территориядә аз үтеп керә торган локаль югары геотейстоцен-гомоценлы аллювиаль горизонт урнашкан. Горизонт Кисмәс елгасы һәм Кече Мишә елгаларының һәм аларның кушылдыкларының беренче-икенче су астында кала торган террасаларның аллювиаль катламнарына яраклаштырылган.

Су сеңдерә торган токымнар исәбенә төрле уалып торучан вакташ һәм чуерташ катыш комнар керә. Горизонт урнашкан беренче өслек басымсыз. Су үткәрелә торган токымнар егәрлеге 0-5 м булган кече һәм урта күкертле комнар белән характерлана, алар нигездә балчык калынлыгында линзалар һәм төрле катламнар рәвешендә очрый.

Статик дәрәҗә өслектән 0-8 м тирәнлектә урнашкан. Горизонтны тукландыру атмосфера явым-төшемнәрен инфильтацияләү, шулай ук югары казандагы югары су агызу системасының җир асты суларын бушату хисабына башкарыла. Эшкәртелгән су елгаларга агызыла.

Горизонттагы сулар күбесенчә сульфат-гидрокарбонат кальций яки магний-кальций, минерализация белән 2,3 г/дм$^3$ кадәр минеральләшәләр гомуми катылыгы 20 ммоль/дм$^3$ җитә. Үзенең сыйфаты буенча горизонттагы җир асты сулары эчәргә яраклы түгел.

Түбән Уржум ярусының түбән горизонтына караган карбонат-терриген комплексы территориядә бөтен җирдә таралган.

Комплексның характерлы үзенчәлеге - аның ике катлы корылмасы, кисемнең өске өлешендә ярыкланган известь катламнары булган йомшак цементланган комлы токымнар өстенлек итә. Комлык егәрлеге 20-25 метрга җитә. Комплексның аскы өлешендә су үткәрелә торган токымнар булып известьташлар һәм мергельләр тора, алар, кагыйдә буларак, төрле гипсометрик дәрәҗәләрдә һәм су кудыргыч балчык катламнарына бүленгән. Су үткәрә торган катламнарның егәрлеге 0,5-3,0 тәшкил итә, статик дәрәҗәләр 0-20 м тирәнлекләрендә урнашкан. (абс.күрсәткеч 135-160 м)

Түбән Уржум комплексын тукландыру атмосфера явым-төшемнәрен инфильтацияләү хисабына, ә субүләрләрдә – югары уржум комплексыннан су агу хисабына башкарыла. Бушануы чишмә агымы юлы белән чокыр өслекләре, шулай ук түбән булган су горизонтлары аша башкарыла. Җир асты суларының чыгуы пластлы үтү белән характерлана. Коры үзәннәрнең өслегендә су агымнары формалаша, алар 1 л/с артмый.

Суларның химик составы гидрокарбонат, кальций, магний-кальцийдан тора, минерализациялеге 0,3-0,5 г/л тигез, суның гомуми катылыгы 4,4 башлап 6,3 мг-экв/л кадәр. Комплекс сулары, коеларны туендыру һәм чишмәләрне каптажлау юлы белән, җирле халык тарафыннан кулланыла.

Югары казандагы су алып килүче территориядә карбонат свитасы бөтен җирдә таратылды. Свитның көндезге өслегенә елга үзәненең аскы өлеше чыга.

Иң еш очрый торган токымнар югары казан ярусының түбәсенә һәм калын табанына туры китерелгән ярыкланган ком белән характерлана. Составында булган токымнарның егәрлеге беренче метрлардан 20 метрга кадәр үзгәреп тора.

Комплекс сулары тыгыз булып тора. Скважиналарда статистик дәрәҗәдәге тирәнлек 15-35 м биеклектәге субүләрләрдә 35-50 м тәшкил итә, бу 130-155 м абсолют билгегә туры килә.

Су белән тәэмин итү тигез түгел. Скважиналарның чагыштырма дебитлары елгалар арасында 10.01-1.75 л/с кадәр үзгәрә, ә үзәннәрнең түбән өлешләрендә 8,3 л/с җитә. Чишмәләрнең дебиты 1-2 алып 7 л/с арасында тирбәлә.

Югары казан свитасының җир асты суларын тукландыру-югарыдагы катламнардан арыну, ә елгаларның үзәннәре төбендә-түбән булган су тарату бүлекчәләрен бушату хисабына башкарыла. Җир асты суларын бушату чишмә агымы, субакваль рәвештә елга үзәнендәге дә хисабына да башкарыла.

Җир асты сулары вертикаль гидрохимик зона белән характерлана. Җир асты суларының химик составы коры калдык зурлыгы 0,3-0,5 г/дм$^3$ булган гидрокарбонат кальцийлардан үзгәрә$^3$ коры калдыклы гидрокарбонат-сульфат корылмаларына – 2,5 г/дм$^3$ кадәр гомуми катгыйлык белән 30 мм / дм$^3$ характерлана.

Хуҗалык-эчәр су белән тәэмин итү өчен яраклы төче җир асты сулары җирле дренажлау базисыннан югарырак урнашкан киселешнең өске өлешенә туры китерелгән. Югары казандагы су свитасы әлеге территориядә су белән тәэмин итү чыганагы булып тора.

Югары казан комплексы җир асты суларының сыйфаты «Эчә торган су...» СанПиН 2.1.4.1074-01 таләпләренә туры килә (кушымтаны карагыз).

## 4. СУ АЛУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫНЫҢ САНИТАР САКЛАУ ЗОНАЛАРЫ ИСӘПЛӘМӘСЕ

Гидрогеологик исәп-хисаплар буенча, хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларын санитар саклау зоналарының 2 һәм 3 пояс зоналарының чикләрен билгеләү өчен, рекомендацияләр нигезендә (1.1.2 пункты), аның тирәсендә җир асты суларының пычрануын булдырмау өчен, су алуга һәм су алу районында су алу катламына пычрату мөмкинлеген булдырмый торган махсус чаралар гамәлгә ашырыла торган өч поястан торган санитар саклау зонасы булдырылырга тиеш.

Санитра саклау зонасының беренче поясының чиге СанПинның 2.1.4.1110-02 (2.2.1.1 пункт) нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла. Ул саклаулы җир асты суларын кулланганда су алу скважинасыннан кимендә 30.0 м ераклыкта һәм җитәрлек дәрәҗәдә сакланылмаган җир асты суларын кулланганда 50.0 м ераклыкта урнаштырыла.

Санитар саклау зонасының икенче поясы әлеге климат шартлары өчен кабул ителә торган су алуга патоген организмнарның хәрәкәт итү вакыты белән СанПин 2.1.4.1110-02 таләпләренә җавап бирә, сакланылмаган җир асты сулары өчен - Т=400 тәүл., сакланган җир асты сулары өчен Т=200 тәүл. тигез.

Өченче санитар саклау зонасы поясы пычранган суны пояс чикләреннән алып су алу җайланмасына кадәр алга җибәрү шарты өчен су алуны эксплуатацияләүнең проект вакыты күбрәк булырга тиеш (Т=25 ел яки 10 000 тәүлек).

Санитар саклау зонасының беренче поясы чикләрен билгеләгәндә, карала торган җир асты кишәрлегендә югары казан терриаль-карбонат комплексының продуктив горизонты аллювиаль чирек һәм казан катламнарының 80 метрлы сумммар калынлыгы белән каплануын игътибарга алырга кирәк. Катламнарны каплап торучы балчыклы токымнарның суммар егәрлеге 32 метрга тигез. Санитра саклау зонасының барлык өч поясы чикләрендә дә продуктлы горизонт тоташ су алу түбәсенә ия (егәрлеге 17.11 булган тыгыз соры миналар), анда «гифогеологик тәрәзәләр» куелмаган. Бу комплексның җирле туклану мөмкинлегеннән чыгып киткән аллювиаль катламнарның сакланмаган су горизонтлары җитәрлек дәрәҗәдә исәпкә алынмаган. Шулай итеп, югары казан терригия-карбонат комплексының җир асты сулары сакланган булып санала.

1.2.1.4.1110-02 СанПиН 2.1. п. нигезендә табигый сакланган җир асты суларын кулланганда җир асты су белән тәэмин итү чыганагының беренче поясы чикләре су алу җайланмасыннан ерак араларга урнаштырылырга тиеш.

Бүлеп бирелгән территориянең су алу өчен каралган урыны чикләнгән булу сәбәпле, 30 м радиуста беренче пояс скважиналарының күләмен тәэмин итү мөмкин түгел:

- скважиналардан төньяк һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә һәм №2 скважинадан 18 м һәм 24,2 м ераклыкта мунча-кер юу корпусы урнашкан.

2.1.4.110-02 СанПиН 2.2.1.1. пункты нигезендә, саклаулы җир асты суларын эксплуатацияләүче объект территориясендә урнашкан су алу җайланмалары өчен туфрак һәм җир асты суларының пычрану булдырмый торган беренче санитар саклау зонасы поясы күләмен Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте органнары белән килештереп, гидрогеологик нигезләү шарты белән кыскарту рөхсәт ителә.

Нәтиҗәле су китерү комплексының өслеге пычранудан югары дәрәҗәдә саклануын, шулай ук учреждение территориясенең санитар яктан уңайлы булуын исәпкә алып (учреждение территориясе койма белән әйләндереп алынган, бу аны туфрак һәм җир асты суларын пычранудан саклау мөмкинлеге тудыручы объект буларак карарга мөмкинлек бирә, су алу җайланмасы территориясе коймасы белән әйләндереп алынган, скважина үзе павильонда урнашкан), ягъни җир асты суларының пычрану мөмкинлеге бетерелгән.

2.1.4.110-02 СанПиН 2.2.1.1 пункты һәм «Хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларын санитар саклау зоналары пояслары чикләрен билгеләү өчен гидрогеологик исәп-хисаплар буенча тәкъдимнәр» дип аталган пункты нигезендә, ерактагы скважиналардан 15 м радиуслы су алу зонасының беренче поясын кыскарту рөхсәт ителә (2.1.4-1110-02 СанПиН кагыйдәләрендә билгеләгән барлык чараларны үтәү һәм дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелек үзәге белән килештерү шарты белән). ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» су алу җайланмасының беренче поясының план-схемасы 5 нче рәс. тәкъдим ителгән.

Санитар саклау зонасының икенче һәм өченче поясы чикләрен билгеләү өчен санитар саклау зонасының «Хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларын санитар саклау зоналарының 2 һәм 3 поясы чикләрен билгеләү өчен гидрогеологик исәп-хисаплар буенча рекомендацияләр» (М., ВНИИВОДГЕО, 1983, 102 бит) дип аталган формулаларыннан файдаланабыз.

Санитар саклау зонасының икенче поясы чиге гидродинамик исәп-хисаплар белән, өске пычранудан саклану дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнә.

Су алу җайланмасының микроб пычранудан саклану шартларын бәяләгәндә, санитар саклау зонасы поясы күләме Т = Тм вакытыннан чыгып билгеләнә, монда Тм – бактерияләрнең тереклек итү вакыты. Продуктлы су куу горизонтының пычрануы өслектән, атмосфера явым-төшемнәре белән бергә, аэрация зонасы аша, грунт сулары дәрәҗәсенең ирекле өслегенә, ә аннары, су белән баетылган токымнарның катлаулы калынлыгы аша нәтиҗәле су горизонтына вертикаль менү юлы белән, аэрация зонасы аша ирекле инфильтация юлы белән чыгарга мөмкин. Димәк, аэрация зонасы аша төп эксплуатацион катламга кадәр пычранган суларны вертикаль буенча алдан исәпләргә кирәк.

## 6. ҖИР АСТЫ ЧЫГАНАКЛАРЫНЫҢ САНИТАР САКЛАУ ЗОНАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘГЕ ЧАРАЛАР

### 6.1. Санитар саклау зонасы поясы буенча чаралар

Санитар саклау зонасының беренче поясы территориясе өслек агымын читкә бүлеп җибәрү буенча планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Корылмаларга керә торган юллар каты өслеккә ия булырга тиеш.

Санитар саклау зонасының 1 поясында түбәндәгеләрне эшләү тыела:

- Биек кәүсәле агачлар утырту;
- Су үткәрү корылмаларын эксплуатацияләүгә, реконструкцияләүгә һәм киңәйтүгә турыдан-туры катнашы булмаган барлык төзелеш эшләре;
- Агулы химикатлар һәм ашламалар куллану;
- Кешеләргә яшәү.

Биналар агымсуларның якындагы көнкүреш яки сәнәгать канализацияләре яки җирле чистарту станцияләренә караган санитар саклау зонасының беренче поясыннан читтә урнашкан чистарту корылмаларының җирле станцияләренә караган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Санитар саклау зоналарының беренче поясында урнашкан су корылмалары, скважина тамаклары, резервуарларның люклары һәм сиптерү торбалары һәм насосларга тутыру җайланмалары аша эчә торган суның пычрануын булдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

Барлык су алу җайланмалары проект җитештерүчәнлеге үткәргечен эксплуатацияләгәндә факттагы дебитның санитар саклау зонасы чикләрен проектлаганда һәм нигезләгәндә туры килү-килмәвен системалы тикшерү өчен кирәкле аппаратура белән җиһазландырылырга тиеш.

6.2. Санитар саклау зонасының 2 һәм 3 поясы буенча чаралар

1. Су горизонтларының пычрану мөмкинлеге булган өлешендә куркыныч тудыручы барлык иске, гамәлдә булмаган, дефектлы яки дөрес файдаланылмый торган скважиналарны ачыклау, тампонлау яки торгызу.

2. Яңа скважиналар бораулау һәм туфрак катламын бозу белән бәйле яңа төзелеш дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелек үзәге белән мәҗбүри килештерү вакытында башкарыла.

3. Файдаланылган суларны җир асты горизонтларына ташлауны, каты калдыкларны җир өстенә чыгаруны һәм җир асты байлыкларын чыгаруны тыю.

4. Ягулык-майлау материаллары, агу химикатлары һәм минераль ашлама складларын, промстоклар, шлам саклау складларын һәм җир асты суларының химик пычрану куркынычын тудыра торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны урнаштыру, геологик контроль органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән санитар-эпидемиологик күзәтчелек булганда, сакланган җир асты суларын кулланганда гына, санитар саклау зонасының өченче поясы чикләрендә рөхсәт ителә.

5. Кулланыла торган су горизонтлары белән турыдан-туры гидрологик бәйләнешкә ия булган өске суларны санитар саклау буенча кирәкле чараларны үз вакытында үтәү.

6. Торак пункт һәм башка объект территорияләрен санитар төзекләндерү буенча чараларны үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрә торган киртәләр урнаштыру, өске агымның бүленешен оештыру һ. б.);

су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларының санитар саклау зонасы чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- җир асты суларының микробды пычрану куркынычын тудыра торган зиратлар, үләт базлары, ассенизация кырлары, фильтрация кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм башка объектларны урнаштыру;
- ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;
- төп кулланылыштагы урманнарны кисү һәм реконструкцияләү.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. «Халыкның санитар-эпидимиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).
2. «Су белән тәэмин итү һәм су үткәрү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)
3. «Су белән тәэмин итү, тышкы бәйләнешләр һәм корылмалар» Төзелеш нормасы һәм кагыйдәләре 2.04.02-82
4. Санитария кагыйдәләре һәм нормалары 2.1. А. 1074-01 «Эчәргә яраклы су. Эчәргә яраклы су белән тәэмин итүнең үзәк ситемасындагы суның сыйфатына гигиена таләпләре. Кайнар су белән тәэмин итү системасының куркынычсызлыгын тәэмин итүгә гигиена таләпләре» (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)
5. Санитария кагыйдәләре һәм нормалары 2.l.4.1 110-02 «Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы сuүткәргечләрне саклауның санитар зонасы»
6. Санитария кагыйдәләре һәм нормалары 2.1.5.1059-01 «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре»
7. «Җир асты суларын саклау» нигезләмәсе, ВСЕГИНГЕО, 1985 ел
8. «Хуҗалык-эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарының 2 нче һәм 3 нче поясы чикләрен билгеләүдә гидрогеологик исәпләүләр алып бару өчен рекомендацияләр», ВНИИ «ВОДГЕО» СССР Төзелеш һәм торак коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлыгы, Мәскәү,1983 ел
9. 1:200 000 масштаблы дәүләт гидрогеология картасы күрсәткечләре легендасы, Урта Идел сериясе, Түбән Новгород, 1993 ел